ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ТУРАЙ АВЫЛЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 23 ноябреннән № 1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлегенең
Турай авылында граждannар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында граждannар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Мәйданчыкны урнаштыру, спорт инвентаре сатып алу.

2) Тирәнлек насосын стып алырга.

3. Турай авылының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән граждannар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru "Турай авыл җирлеге" бүлегендә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Турай авыл җирлеге башлыгы А.М.Рахимова